**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июль № 515

г. Казань

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2009 ел, 15 июнь, 394 нче; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче, 2016 ел, 27 июнь, 443 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 пунктның беренче абзацында «15 декабрь» сүзләрен «1 октябрь» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктның беренче абзацында «5 көн эчендә» сүзләрен «ел саен, 1 ноябрьгә кадәр,» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Министрлык тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның категорияләрен торак белән тәэмин итүгә каралган акча кысаларында ел саен, 1 декабрьгә кадәр планлаштырыла торган елда сертификатлар алучы гражданнар исемлеген һәм шул ук елда сертификатлар алуга резервка кертелгән гражданнар исемлеген формалаштыра һәм аларны раслаганнан соң 10 көн эчендә исемлекләрне җирле үзидарә органнарына һәм махсуслашкан оешмага җибәрә.»;

20 пунктта «сертификатлар бланкларын чыгару датасы» сүзләрен «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечен билгели торган боерыгы законлы көченә керү датасы,» сүзләренә алмаштырырга;

33 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Сертификат хуҗасы сертификатны алганнан көннән соң ике атна эчендә аны махсуслашкан оешма раслаган форма буенча торак урын сатып алуга шартнамә төзү өчен махсуслашкан оешмага тапшыра, шулай ук Министрлыкка субсидия акчасын махсуслашкан оешма счетына күчерү турында гариза җибәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков